Ураза бәйрәмен каршылап...

Июнь аеның 28 көнендә безнең район мөселманнары изге Рамазан гаетен каршыладылар. Бөтен мөсельман—якташларыбыз бу бәйрәм көнне якты хисләр, ачык күңел, ару һәм югары фикерләре белән котталәр. Иртә белән Ләмберә районының мәчетләрендә, авылларының барысында да — Аксюнда һәм Татар Тауласында, Ләмберәдә һәм Пензятка, Мельцанинда, Сәрбидә һәм башкаларында — гаетне каршыларга бөтен авылчылар җыелдылар. Аларның арасында, куанычка, күп яшьләр иде, карт абыйлар бер—берләрен, куанып, бәйрәм белән тәбрикләделәр, хезмәтчеләр, укучылар, студентлар...

Кырьви авылының мәчетендә 28-нче июньдә Рамазан гаетенә дүрт йөздән артык мөселман сәгать алтыга җыелды. Крьви авылы яшәүчеләре генә түгел, әмма якын Суркино һәм Шувалово авылларыннан, Саранск шәһәреннән мәчеткә кунаклар җыелды. Мәчетнең имам—хатыбы Рәмис хәзрәт Гөбәйдуллов гыйбадәтне Бәйрәм гаете вәгазе белән башлады. Ул вәгаздә Рамазан аеның изгелеге, кирәклеге, мөһимлеге турында сүз барды. Соңыннан бөтен кешеләр бергә бәйрәм намазын укыдылар. Моның арты Ремис хазрәт хотбә сүзен әйтте — якты Рамазан аеның тарихы һәм югарылыгы турында, тәрәвих укуының мәгнәсен һәм кирәклеген аңлатты, мөселманнарга Кадер кичәнең сәвaплыгы һәм әһәмиятлеге турында сөйләде. Гыйбадәтнең ахырында бөтенесе бергә дога кылдылар һәм якты теләкләр теләделәр. Авыл мөселманнары каршында Рәмис хәзрәт котлау хатларын да укып алды: РФ Мөфтиләр Шурасы, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзәрәте Рәисе Равил Гайнетдиннан һәм Мордовиянең мөселманнар дини җитәкчелегенең мөфтиеннән — Илдус ахзрәт Исхаковтан. Гает намаз—догаларын тәмамлагач, ир—мөселманнар каберстанга ата—бабаларының, ана—сеңелләренең каберләренә, аларның рухларына Корьән укып, дога кылырга бардылар.

Рамазан аеның барышында авылда ике ифтар үткәрелде. 22-нче июльдә 300 ир, ә 23 июльдә 80 хатын—кыз мәчеттә авыз ачтылар. Бу сәвап эшне оештырырга 15 кеше, спонсорлар булып, ярдәм иттеләр. Кадер кичәсендә авыл мөселманнары мәчеттә иргәмәшгә кадәр кадер сурасен, намаз һәм диялар укыдылар.

Күрше Хаҗи авылында да Ураза гаете көнне иртә белән ук мәчет кеше белән тулды. Анда бәйрәм гыйбадәтен авылның карты, хезмәт ветераны, мулла Асым—абый Бикмурзин һәм Саранск шәһәреннән килгән Хаҗида туган Няим—абый Ариков белән алып бардылар.

Щербак авылында йөздән артык кеше Ураза гаетенә авыл мәчетенә җыелды. Изге бәйрәмне каршыларга туган авыларына Щербакның кызлары һәм уллары төрле урыннардан килеп җиттеләр. Гает гыйбадәтен Бөек Ватан сугыш һәм хезмәт ветераны, 90-яшьлек Велиулла абый Асаинов алып барды. Рамазан шәриф аенда Щербак мәчетендә утызга якын кеше өчен ифтар үткәрелде. Бу сәвапле эшнең оештыруына авыл кызы Наилә Фатих кызы Ахметова бик зур ярдәм кылды.

Дини дәресләр

Һәр игелек — садака

«Әгәр ачулашкан ике кешене дуслаштырсаң, бу эшең сиңа сәдака булыр, әгәр кешегә атланып утырырга яки йөген куярга ярдәм итсәң, бу эшең дә сәдака булыр, һәр яхшы сүз — сәдака, гыйбадәт кылу юлында ясаган һәр адымың — сәдака, юлдан башкаларга зыян китерерлек нәрсәләрне алып ташлавың да синең өчен сәдака була» (хәдис).

Аллаһыдан куркучы мөселманга рәхмәт ишекләре һәрвакыт ачык. Һәм ул бу ишекләргә Аллаһының мәрхәмәтенә ирешү һәм Аның юмарт бүләгенә лаек булу өчен кирәргә омтыла.

«Һәр мөселман сәдака бирергә тиеш». Кешеләр: «Әй, Аллаһының Илчесе! Әгәр аның сәдака бирергә бернәрсәсе дә булмаса?» — дип, сораганнар. Рәсүлуллаһ: «Аның үз куллары белән эшләп, үзенә файда китерүе аңа сәдака булыр», — дип, җавап биргән. Кешеләр сораганнар: «Әй, Аллаһының Илчесе! Әгәр ул моны эшли алмаса?» Ул: «Башка кешеләрдә рөхсәт ителгән һәм игелек китерә торган эшләргә теләк уятсын», — дигән. Кешеләр тагы сораганнар: «Әгәр ул моны да эшли алмаса?» Рәсүлебез: «Начарлык эшләүдән тыелсын, бу да аңа сәдака булып язылыр», — дип җавап биргән.

Апас төбәк тарихы музее

Ләмберә авылыбызда үткән Сабан туе әлегә кадәр күңелләргә якты нурлар җибәреп тора. Андагы бәйрәм мәйданы, җыр—биюләр, суеннар, данлы керәш батырлары, озак онытылмас. Ә күпме кунаклар килде безгә, нинди генә кызыклы, яхшы кешеләр белән танышырга туры килмәде! Шушыларның берсе белән безнең хәбәрчебез дә танышты һәм интервью алды. Бу кеше — Апас туган якны өйрәнү музееның җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәнният хезмәткәре, оста гармунчы һәм башка инструментларда уйнатучы Рәмис Гусман улы Ногманов (гармунчылар төркемендә, безнең сәхнәбездә, ул тыңлаучыларның исләрен китереп, бик матур уйнап алды). Ник без аңа мондый игътибар бирдек? Чөнки Ләмберә районында да мондый музейның кирәклеген, яшь буынга файдалыгын сизеп, «краеведческий» дигән музей ничәнче ел инде оештырылырга җыена. Шуңа күрә, кунакларыбызның тәҗрибәсе (опыт) безгә кызыклы һәм кирәкле дип, күренде.

— Төбәк тарихы музее Апаста 1991 елда, октябрь аенда ачылды. 1996 елдан — ул Татарстанның дәүләт музее филиалы була, 2001 елдан — ТР—ның Милли музее, ә 2007-дән муниципаль музеее дип санала. Ул бер катлы бинаны били. Экспозиция мәйданы — 200 квадрат метр. Төп фондыбызда — 902 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция өч бүләктән тора. Этнография бүлеге көнкүреш кирәк-яраклары, Казан татарларының тормыш рәвеше һәм кәсепчелеге белән таныштыра. Музейда чигүле һәм тукылган сөлгеләр, алмагачыннан эшләнгән карават (20 йөз башы), удмурт челтәрләре (20 йөз башы) һәм башкорт сөлгесе (18 йөз ахыры) коллекцияләре урын алган. Җ. Вәлидинең шәхси буфеты күргәзмәгә куелган. Төбәктә булган гражданнар сугышына багышлангaн бүлектә сугыш кораллары фрагментлары, документлар һәм гражданнар сугышында катнашучыларның фотографияләре, чех-словак корпусы частьләре белән бәрелешләр, aлпавыт утарларының тар-мар ителүе турында материаллар бар. Экспозициянең Бөек Ватан сугышы турындагы бүлеге Апас районында туган Советлар Союзы Геройлары Д.И. Горбунов, С.Х. Кәримов, Р.А. Абзалов, Дан орденының тулы кавалеры - И.Н. Насыйбуллин, Нюрнберг процессында катнашкан контр-адмирал И.М. Золин белән таныштыра. 1942 дә оборона корылмаларын кабул итү-тапшыру акты аерым игътибарга лаек (карагыз Казан каймасы). Археологиятә, районның хәзерге тарихына, шулай ук танылган шәхесләр биографиясенә багышланган бүлекләр каралган, концепциясе эшләнгән яңа экспозиция төзелеше бара. Социалистик Хезмәт Геройлары - М.С. Кәлимуллина, Ә.М. Маликова (Шәфигуллина), С.С. Гөбәйдуллин, Г.С. Галиев, В.Г. Садовниковлар турында материаллар тупланган. Аеруча мөһим коллекцияләргә Казан татарларының 19 йөз ахыры - 20 йөз башында чигелгән һәм тукылган әйберләре (100 дән артык саклау берәмлеге), 1958 елда Турай авылында табылган хәзинәдән алынган савыт-саба (фарфор, пыяла, бакыр савытлар, 10 саклау берәмлеге), төрле илләрнең янгынга каршы хезмәтенә нисбәтле, 1920-2000 елларда чыгарылган значоклар (429 саклау берәмлеге) керә. Музей ел саен мөселманча Яңа ел - Нәүруз (21 март), «Каз өмәсе» (10 декабрьдә), музей ачылган көнен (14 октябрьдә) үткәрә.

Рамис әфәнде күпкырлы талант иясе. Ул төрле уен коралларын үзләштергән: хромка, тальян, саратов гармуны, баян, курай, кубыз, калакларда уйный, «Тынгысызлар» исемле ирләр фольклор ансамблен җитәкли.

Рәмис Ногманов уенчы бала булып дөньга килгән. Аларның җидесе исән калган, барысы да җыр—биюгә, музыкага сәләтле. Үзенең әйтүе буенча, тальянда ул биш яшендә ук уйный башлаган. «1951-нче елны абый гармун алып кайткан иде», — дип искә төшерә Рәмис әфәнде. Абыйсы эшкә чыгып киткәндә, кызыксынучан малай уен коралын шкаф башыннан алып, үзлегеннән өйрәнә торган булган. Хәзер дә зур бәйрәмнәрдә, төрле мәҗлесләрдә уйный. Аның репертуарында — авыл көйләре, бию көйләре, татар композиторларының җырлары.

Авылым тавышлары

Выпуск № 48

Хәдисләр

«Сезгә нинди кешеләргә җәһәннәм уты хәрам булуын хәбәр итимме? — Ул табигате каты булмаган, мөлаем, йомшак күңелле, халыкка якын булган, эшләрне авырайтмаган, җиңел табигатьле кешеләр».

«Аллаһы Тәгалә һәр эштә йомшаклыкны сөя».

«Әгәр күңелеңә начар уй килсә, аны күңелеңнән чыгарып ташла».

Мәкальләр

Байлык белән торылмый, холык белән торыла.

Диңгезне күмеп була, адәмнең комсызлыгын күмеп булмый.

Еланның аягын күрмәссең, саранның сыен күрмәссең.

Саран бай хәерчедән ярлырак.

Мөселман дөньясы

Россия Иҗтимагый палатасы ифтары уздырылды

Россия Иҗтимагый палатасы һәм Мәскәү мөфтияте беренче тапкыр бергә Мәскәүдә ифтар уздырдылар. Әлеге чарада Россия сәясәтчеләре, депутатлары, хокук саклаучылар, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, төрле дин әһелләре мөселманнарны якынлашып килүче Ураза бәйрәме белән котладылар.

Мәскәүдә Ураза гаете намазына 230 мең мөселман килгән

28 июнь көнендә мөселманнар Ураза гаетен бәйрәм иттеләр. Гает намазы Мәскәүдән 6 мәчетендә укылды. Анда якынча 230 мең мөселман җыелган. Мәскәү янында гает намазы өчен тагын 29 мәйдан булдырылган иде. Алар Балашиха, Звенигород, Наро—Фоминск, Одинцово, Воскресенск, Домодедово, Можайск һәм башка шәһәрләрдә урнашкан. Мәскәүнең Выползов тыкрыгында урнашкан шәһәрдә иң зур мәчетнең гыйбадәтләр залы иртәнге 5 сәгатьтә ук ачылды. Анда РФ Мөфтиләр Шурасы, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзәрәте Рәисе Равил Гайнетдин дә катнашты. Мөселманнарны Ураза гаете белән РФ Президенты Владимир Путин да котлады. «Мөселманнар җәмгыят Россия тормышында актив катнаша, халыклар конфессиясе диалогы үсешенә сизерлек өлеш кертә, дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар белән берлектә, хәйрия һәм агарту эшләренә, үсеп килүче буынны тәрбияләүдә хезмәттәшлек итә», диелгән РФ Президенты котлавында.

Сәләмәтлек

«Физик күнегүләр мускуллар өчен түгел, ми өчен дә файдалы», — дигән фикергә килгән Колумбия университеты медицина үзәге галимнәре. Алар үткәргән тәҗрибә буенча, физик күнегүләр ми эшчәнлеген тизләтә һәм яхшырта икән. Тәҗрибәләр 11 сәламәт кеше белән үткәрелгән. Аларны өч ай буе физик күнегүләр белән шөгыльләнә башлаганчы һәм шөгыльләнгәннән соң магнит—резонанслы аппарат белән тикшергәннәр. Бу эксперимент баш миендәге хәтер өчен җаваплы урыннарда күзәнәкләр артканын күрсәткән.

Файдалы киңәшләр

С витамины иң күп булган җимеш — гөлҗимеш

Лимон суы вирусларны үтерә, йокысызлыктан дәвалый.

Дару үләннәреннән җир өсте өлеше күбесенчә чәчәк атканда җыела.

Өйдә черки, чебен күп булганда, 20-30 грамм әче әремне 1 литр суда 15 минут кайнатып, суын бүлмәгә беркиләр.

Тешләрегезне саклагыз

Галимнәр җиләк—җимеш соклары тешләр өчен водород перекисенең 6 процентлы эремәсенә караганда да зыянлырак булуын ачыклаганнар. Тикшерүчеләр теш эмале үзгәрешләрен микроскоп аша караганнар — җиләк—җимеш кислоталары шул кадәр көчле ки, аларны эчкәндә теш эмале юылып кына төшә икән. Кеше әфлисун согын эчкәндә эмаль ныклыгы 84 процентка кими. Хәтта тешне агарта торган төрле препаратлар да моның кадәр начар йогынты ясамый икән.

Теш табиблары сокларны бер сулыштан эчеп бетерергә киңәш итә. Озаклап «чөмереп утыру» тешләргә зур зыян сала. Шулай ук тешләрнең составында фтор булган теш пастасы белән юарга һәм елына бер тапкыр гына булса да теш табибына барып, фторлы лак белән тешләрне эшкертергә киңәш итә.